# КАРАР

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге составына керүче Троицкий торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2019 елның 15 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 15 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлеге Троицкий торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча узәк урам буенча юллар салу һәм зиратка керү өчен вак таш сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 64 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 42 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 42 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге составына керүче Троицкий торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлеге Троицкий торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме.. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча узәк урам буенча юллар салу һәм зиратка керү өчен вак таш сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Сосновка авыл җирлеге сайтында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыснында рәислск итүчс,
Сосновка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Бурчин

Совет Сосновского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан ИНН 1630003193